**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШЛЫГЫ**

423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-14

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА АКТАНЫШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел. 3-44-44, факс 3-44-14

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

______________ 12.12.2023 ПГ-50 № ______

Актаныш муниципаль районы
территориясендә янгынга каршы махсус
режим урнаштыру турында

Яңа ел һәм Раштуа бәйрәм чараларын уздыру чорында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү, гражданнарның сәламәтлеген һәм гомерен, физик һәм юридик затларның мөлкәтен, дәүләт яисә муниципаль мөлкәтне янгыннардан саклау максатларында, “Янгын куркынычсызлыгы турында” 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясы һәм “Янгын куркынычсызлыгы турында” 1993 елның 18 маендагы 1866-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 25 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елның 08 декабрендәге 1581 номерлы карары нигезендә,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 2023 елның 25 декабреннән 2024 елның 8 гыйнварына кадәр, Актаныш муниципаль районы территориясендә янгынга каршы махсус режим урнаштырырга.

2. Махсус янгынга каршы режим гамәлдә булган чорда 1- 3 куркыныч класслы пиротехник эшләнмәләрне (Бенгал утларыннан, хлопушкалардан тыш) түбәндәге чикләрдә куллану тыела:

сәнәгать, транспорт инфраструктурасы объектлары (автомобиль юлларыннан тыш), ягулык-энергетика комплексы (шул исәптән линияле) чикләреннән 500 метр;

торак-коммуналь хуҗалык, авыл хуҗалыгы объектлары чикләреннән, кешеләр күп була торган объектлар, автомобиль юллары, хосусый йортлар чикләреннән 30 метр;

Күпфатирлы торак йортлардан 30 метр.

3. 30 һәм 500 метрлы зоналарда махсус янгынга каршы режим гамәлдә булган чорда пиротехник эшләнмәләр куллану тыелган объектларның исемлеген расларга.

4. Актаныш муниципаль районының җирле үзидарә органнарына әлеге карар белән расланган исемлеккә кертелмәгән махсус янгынга каршы режим гамәлдә булган чорда пиротехник эшләнмәләр куллану тыелган өстәмә объектларны билгеләргә тәкъдим итәргә.

5. Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлегенә, “Мәгариф идарәсе” МКУнә, социаль һәм агарту эшләре бүлегенә, ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау бүлегенә, “Актаныш район үзәк хастаханәсе” ДАССУнә тәкъдим итәргә:

ведомство буйсынуындагы оешмаларда Яңа ел һәм Раштуа бәйрәм чараларын әзерләү һәм уздыру чорында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү чаралары комплексын гамәлгә ашырырга;

янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә өстәмә һөнәри белем бирү программалары буенча, Яңа ел һәм Раштуа бәйрәм чараларын уздыру өчен җаваплы вазыйфаи затларны укытуны оештырырга;

Яңа ел һәм Раштуа бәйрәм чараларын уздыру чорында дежур персонал санын

арттырырга;

ведомство буйсынуындагы оешмаларның ябык биналарында ут эффекты булган пиротехник эшләнмәләрне саклауны һәм куллануны булдырмаска.

6. “ТР буенча федераль янгынга каршы хезмәтнең 15 отряды” 103 нче янгын сүндерү бүлегенә, ТР Россия буенча гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Баш идарәсе күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактика эше идарәсе буенча Актаныш һәм Минзәлә муниципаль районнары буенча күзәтчелек һәм профилактика эшенең районара бүлегенә тәкъдим итәргә:

Яңа ел һәм Раштуа бәйрәм көннәрендә янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәү турында халыкка мәгълүмат бирүне оештырырга:

балаларның Яңа ел һәм Раштуа бәйрәм чараларын үткәрү урыннарын исәпкә алырга, җәлеп ителгән объектларда закон кысаларында күзәтчелек һәм профилактика чаралары комплексын үткәрергә;

Россия Эчке эшләр министрлыгының Актаныш районы буенча бүлеге хезмәткәрләре белән берлектә пиротехник эшләнмәләрне ачыклау һәм сатуны чикләү буенча территорияләргә барып тикшерү уздырырга.

7. Россия Эчке эшләр министрлыгының Актаныш районы бүлегенә хезмәткәрләр патрульлек итү маршрутларында хезмәт иткәндә янгын очракларын ачыклауга, кешеләрне коткару, зыян күрүчеләргә беренчел табибка кадәр ярдәм күрсәтү, беренчел (кул астындагы) янгын сүндерү чаралары белән янгын сүндерүчеләр килгәнче янгын чыганакларын локальләштерүгә көч һәм чаралар юнәлтергә тәкъдим итәргә.

8. Актаныш муниципаль районының Башкарма комитетына, авыл җирлекләре башлыкларына:

пиротехник эшләнмәләрне гамәлгә ашырганда һәм кулланганда янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә Россия Федерациясе законнарының төгәл үтәлешен тәэмин итәргә;

әлеге карарны үтәү өлешендә халык, юридик затлар, шул исәптән пиротехник эшләнмәләр белән ваклап сатуны гамәлгә ашыручылар арасында, шулай ук пиротехник эшләнмәләрне сату һәм куллану вакытында янгын куркынычсызлыгы таләпләрен аңлату эшен оештырырга;

2023 елның 20 декабренә кадәр гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе утырышында Яңа ел һәм Раштуа бәйрәм чараларын уздыру урыннарының янгын куркынычсызлыгы торышы мәсьәләләрен карарга;

ирекле һәм муниципаль янгын сагы әгъзаларының янгын сүндерү техникасы белән тәүлек буе кизү торуын оештыру буенча чаралар комплексын гамәлгә ашырырга;

оператив хезмәт һәм оешмаларны Яңа ел бәйрәм чараларына һәм түбән температуралар чорына әзерләү мәсьәләләре буенча фикер алышырга;

янгынга каршы тышкы су чыганакларыннан су алу өчен шартлар тудыру буенча чаралар комплексын гамәлгә ашырырга, шул исәптән төзек булмаган су чыганакларын ремонтлауны оештырырга, елның кышкы вакытында су җыю башняларын су алу өчен җайланмалар белән җиһазландырырга, табигый сулыкларны – туңмый торган бәкеләр белән тәэмин итәргә, су чыганакларына керү юлларын кардан чистартуны оештырырга;

халыкка янгынга каршы су чыганаклары янында шәхси автотранспортны парковкалауның рөхсәт ителмәве турында хәбәр итәргә, кирәк булганда янгын сүндерү автомобильләренә су чыганакларына керүне кыенлаштыра торган автотранспортны эвакуацияләүне оештырырга;

күзәтчелек эшчәнлегенең территориаль бүлекләре һәм күзәтчелек эшчәнлеге идарәсенең профилактик эше һәм Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсенең һәм Россия Эчке эшләр министрлыгының Актаныш районы буенча бүлеге белән килештереп, пиротехник

эшләнмәләрне сату урыннарында куркынычсызлыкны тәэмин итү чараларын күрергә;

пиротехник эшләнмәләрне саклау һәм сату шартларын мониторинглау буенча комиссияләр төзергә;

урам чыршыларын бизәү сыйфатында сертификацияләнгән электр гирляндаларын файдаланырга;

пиротехник эшләнмәләрне кулланганда куркынычсызлык таләпләрен үтәү чаралары турында халыкка мәгълүмат бирү буенча эш оештырырга;

янгыннар белән вәзгыять катлауланган очракта, тиешле территорияләрдә пиротехник эшләнмәләр куллануны тыярга;

2023 елның 25 декабренә кадәр һәр торак пунктта пиротехник эшләнмәләр куллану урынын билгеләргә, «Төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны саклау турында» 2010 елның 12 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәүне тикшереп торуны тәэмин итәргә һәм бу хакта халыкка хәбәр итәргә;

2023 елның 31 декабреннән 2024 елның 8 гыйнварына кадәр күпбалалы, имин булмаган гаиләләргә, ялгыз өлкән яшьтәге гражданнарга аерым игътибар биреп, торак йортларда гражданнар белән янгын куркынычсызлыгы чаралары турында профилактик әңгәмәләр уздыруны оештыру максатыннан, дәүләт янгынга каршы хезмәте хезмәткәрләреннән, ирекле янгын күзәтчелеге әгъзаларыннан, Россия Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләренең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча федераль хезмәте идарәсе территориаль бүлекчәләре хезмәткәрләреннән һәм полициядән (килешү буенча), җирле үзидарә органнары, муниципаль район башкарма комитетының административ комиссиясе, халыкны социаль яклау бүлеге хезмәткәрләреннән профилактика төркемнәре төзергә.

9. Тәкъдим итәргә:

пиротехник эшләнмәләрне җитештерү, саклау һәм сату эшчәнлеген гамәлгә ашыручы юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга пиротехник эшләнмәләрен сатканда һәм кулланганда янгын куркынычсызлыгы өлкәсендәге Россия Федерациясе законнарын тайпылышсыз үтәүне тәэмин итәргә;

автозаправка станцияләре һәм комплексларын эксплуатацияләүче юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга электр гирляндаларын һәм таләп ителә торган шартлаудан саклау дәрәҗәсе булмаган башка иллюминацияне, территорияләрне һәм югарыда күрсәтелгән объектларның биналарын бизәгәндә куллануны төшереп калдырырга;

Татарстан Республикасы территориясендә күпләп һәм ваклап сату белән шөгыльләнүче оешма җитәкчеләренә законнарда билгеләнгән тиешле сертификатлары (ярашлы декларацияләр) булмаган пиротехника эшләнмәләрен һәм электр гирляндаларын, шулай ук техник документациядә янгын куркынычлыгы күрсәткечләре һәм алар белән эш иткәндә янгын куркынычсызлыгы чаралары күрсәтелмәгән яңа ел бизәкләре, ясалма чыршыларны сатуны булдырмау чараларын күрергә;

баланста янгынга каршы тышкы су белән тәэмин итү чыганаклары булган оешмалар җитәкчеләренә аларны төзек хәлдә тотуга юнәлдерелгән чаралар күрергә, шул исәптән янгын сүндерү машиналарын су чыганакларына кертүне тәэмин итәргә, шулай ук су чыганакларын вакытынд кар һәм боздан чистартырга;

гражданнарга дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына «112», «01», «02» ашыгыч оператив хезмәтләре телефоннары буенча, шулай ук мөмкин булган башка ысуллар буенча пиротехник эшләнмәләрне санкцияләнмәгән куллану очраклары турында мәгълүмат бирергә.

11. «Татмедиа» АҖ филиалы «Актаныш информ»га Яңа ел һәм Раштуа бәйрәм көннәрендә янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәү турында халыкка мәгълүмат җиткерүне тәкъдим итәргә.

12. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетына йөкләргә.

Район башлыгы Л.Р.Зарипов

Актаныш муниципаль районы
Башлыгы карары белән расланган
12.12.2023 ел, № ПГ-50

30 һәм 500-метрлы зоналарда янгынга каршы махсус режим гамәлдә булган чорда пиротехник эшләнмәләр куллану тыела торган объектлар исемлеге

500 метрлы зона

1. Сәнәгать объектлары:
төзелеш сәнәгате оешмалары;
агач эшкәртү оешмалары;
терлек продуктларын эшкәртү оешмалары;
азык-төлек матдәләрен эшкәртү буенча сәнәгать объектлары һәм производстволары;
минераль ягулык яндырганда электр һәм җылылык энергиясе җитештерү оешмалары;
микробиологик сәнәгать оешмалары.
2. Транспорт инфраструктурасы объектлары:
вокзаллар;
транспорт чаралары хәрәкәте белән элемтә, навигация һәм идарә системалары объектлары.
3. Ягулык-энергетика комплексы объектлары:
электр энергетикасы, нефть чыгару, нефть эшкәртү, газ объектлары;
нефть продуктлары, җылылык һәм газ белән тәэмин итү объектлары;
ягулык-энергетика комплексының линия объектлары (электр челтәрләре, магистраль газүткәргечләр, нефть үткәргечләр).

30 метрлы зона

4. Автомобиль юллары.
5. Торак-коммуналь хуҗалык объектлары: торак фонды, кунакханәләр, тулай тораклар;
торак-коммуналь хуҗалык объектларына техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау өчен билгеләнгән оешмалар;
халыкны газ, җылылык һәм электр белән тәэмин итү объектлары.
6. Авыл хуҗалыгы объектлары:
терлек асраучы хуҗалыклар (дуңгыз, сыер абзарлары, питомниклар, ат абзарлары, терлек фермалары);
кошчылык фермалары;
теплица һәм парник хуҗалыклары;
җиләк-җимеш, яшелчә, бәрәңге, ашлык саклагычлары;
ит, сөт эшкәртү, икмәк һәм икмәк-күмәч ризыклары җитештерү предприятиеләре һәм цехлары;
агулы химикатлар һәм минераль ашламалар саклау складлары;
орлыкларны эшкәртү һәм агулау производстволары;
аммиак складлары;
азык әзерләү цехы, азык-төлек калдыкларын куллануны да кертеп;

йөк автомобильләрен һәм авыл хуҗалыгы техникасын ремонтлау, технологик хезмәт күрсәтү һәм саклау буенча гаражлар һәм парклар;

материал складлар.

7. Кешеләр күп була торган объектлар:

дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының административ биналары;

мәдәният, спорт, мәгариф, социаль хезмәт күрсәтү, сәламәтлек саклау, җәмәгать туклануы объектлары, дәүләт яшьләр сәясәте объектлары;

сәүдә-күңел ачу һәм офис үзәкләре.

8. Яшәү объектлары:

күпфатирлы йортлар;

хосусый йортлар.